ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№2 16 ноябрь 2025 ел

2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Түбән Якый торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагыш авыл җирлеге Түбән Якый торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2026 елда 1 теркем инвалидлардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

-урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү, электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү; лампалар, электр саклый торган яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җайланмалар сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (үлән чабу, чүп-чар җыю, агач кисү хезмәтләре өчен түләү, юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын гидрантын урнаштыру ечен кое кору, материаллар, җиһазлар сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү, янгын гидрантларын, янгын букчаларын, КПА колонкаларын, янгын сүндергечләрне, янгын җиңсәләрен, мотопомпаларны сатып алу һәм урнаштыру);

- ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (лак-буяу материалы сатып алу, зират коймасын буяу, үләннәр чабу, агач һәм куакларны кисү, чүп җыю; гербицид сатып алу, тоташ гербицид белән химик эшкәртү)

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Мәлбагыш авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Мәлбагыш авыл җирлеге башлыгы А.Й.Әхмәтшин